ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**30.07.2018**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1529**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Зеленодольск муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлекләре- авыл җирлекләре чикләрендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында» 2017 елның 18 сентябрендәге 2390 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 77 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон һәм «Конкуренцияне яклау турында» Федераль законның 25.1 статьясына ярашлы рәвештә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 18 сентябрендәге 2390 номерлы карары белән расланган, «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Зеленодольск муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлекләре- авыл җирлекләре чикләрендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыруның административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 2 нче бүлектәге 2.5 өлешен 2.5.3 пунктыннан соң түбәндәге эчтәлектәге $2.5^{1}$ өлеше белән тулыландырыргага:

«$2.5^{1}$. Муниципаль җир контроле органы һәм муниципаль җир контроле органы вәкаләтле затларының эшчәнлеген планлы һәм планнан тыш тикшерүләр турында аларның нәтиҗәләре һәм ачыкланган бозуларның нәтиҗәләрен бетерү буенча күрелгән чаралар турында мәгълүмат Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган тикшерүләрнең бердәм реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре нигезендә тикшерүләрнең бердәм реестрына кертелергә тиеш».

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының

(http://pravo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүматы рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2018 елның 19 августында үз көченә керә.

Җитәкче Д.А. Сапожников